Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының илле икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

22 май, 2025 ел № 408

2024 елда Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруны фаразлау планын (программасын) үтәү йомгаклары турында хисап

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 50, 51, 85 статьялары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының «2023-2025 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) раслау турында» 2023 елның 18 маендагы 238 номерлы карары (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2023 елның 7 декабрендәге 291 номерлы карары белән расланган үзгәрешләре белән), Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруны фаразлау планын (программасын) үтәү йомгаклары турында хисапны 2024 елда расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Советы карарына кушымта
22 май, 2025 ел № 408

# 2024 елда Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) үтәү йомгаклары турында хисап

2024 елда муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының «2023-2025 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планын (программасын) раслау турында» 2023 елның 18 маендагы 238 номерлы карары нигезендә (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2023 елның 7 декабрендәге 291 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) гамәлгә ашырылды.

Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның төп бурычы булып Питрәч муниципаль районы җирле үзидарә органнары функцияләрен (вәкаләтләрен) һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнмәгән муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру исәбенә муниципаль милек структурасын оптимальләштерү тора.

2024 елга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планына кертелгәннәр:

- 7 күчемле мөлкәт объекты;
- 4 күчемсез милек объекты.

Хосусыйлаштыру объектларын сатуның башлангыч бәясе «Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 елның 29 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә билгеләнгән базар бәясе нигезендә билгеләнә.

Аукционда катнашуга гаризалар булмау сәбәпле объектлар сатылмады.